Көмеш кыңгырау
№48 (1087)
7 июль
2006 ел

Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА

Чәчәкләр арасында

Болында

Болында аяк усә,
Болында таяк усә.
Сакал да бар, баш та бар,
Уйлый белгән баш та бар,
Чәчәк аткан бер читтә
Озын кәҗә сакалы.
Ат кузгалагы җилдә
Моңсу гына чайкала.
Кереп баскан энәле
Төп-төз шайтан таягы.
Менә сары чәчәкләр-
Яфрагы каз аягы.
Тукранның башы төшкән,
Карга борыны пешкән,
Күгәрченнең күзе бар,
Эт какысы үзе бар.
Хәтфәдәй бәбкә үлән
Иркәли аягымны.
Үзенчә бизи бар да
Минем туган ягымны.

Ландышлар

Яшел күлмәкле ландышлар
Энҗе муенса элгән.
Яз бүләге, якты чәчәк
Хушбуйлар
Сибеп килгән.

Аклык, пакълек тирә-якта,
Чистарынган әрәмә.
Я, ничек кыеп басасың
Бу хуш исле келәмгә?



Үги ана чәчәге

Алтын күз, алтын керфек,
Керфегендә йөз бөртек.
Карның эрүен көтеп,
Беренче чыга төртеп.



Умырзая

Кар-бозны этә-төртә,
Чәчәк бөресе чиртә.
Яз кызы умырзая
Чәчәк ата бик иртә.

Челтер-челтер гөрләвек
Чылата аякларын.
Сагынган умырзаялы
Язын туган якларым.

Тузганак

Кояш кебек түгәрәк,
Сары чәчәк тузганак.
Картайды да агарды,
Оча әнә тузгалап.

Һәр орлыгы канатлы,
Канатлы-парашютлы.
Минде берсе бик биек,
Бигрәк шәп очам, диеп.

Җил исте кинәт кенә,
Болыт каплады күкне.
Тузганакның орлыгын
Яңгыр чылатып үтте.

Авырайды канаты,
Төште җиргә тып итеп,
Үсеп чыгарга кабат
Күмелде бик нык итеп.

Мәкләр

*Мәкләр чәчәк атканнар,
Кызылы бар, алы бар.
Эрерәге, вагы бар,
Түр бакчада тагы бар.*

*Җил генә исеп үтте,
Мәк күлмәген салдырды.
Чәчәкләрне ник инде
Шулай шәрә калдырды?*

*Карасам, һәр сабакта
Яшел, йомры төймәләр.
Җилгә ачуланганнар,
Йодрыкларын төйнәгән.*

*Тагын һөҗүм көткәндәй,
Җилгә каршы басканнар.
Әйтерсең, рингтагы
Нәни батыр боксерлар.*

Мәтрүшкә

*Үйсулыкта, урманнарда
Хуш исе борын яра.
Тамак шешсә, томау төшсә,
Мәтрүшкә була дәва.
Тәмен-исен яратканга
Себеркегә кушалар.
Тәне кызышканнарга да
Эчертергә кушалар.*



Меңъяфрак

*Ак мәтрүшкә дә диләр аны,
Яфраклары мең челтем.
Чәчәкләре ап-ак ярма,
Тәме - исе әчкелтем.*

*Смекталар читтә торсын,
Меңъяфрак җыйсаң җәен.
Күп чирләрдән дәва була
Кайнатып эчсәң чәен.*

Җилдәвекләр

*Язгы җилләрнең бүләге-
Сап-сары җилдәвекләр.
Биш таҗы да янып тора,
Алтын тәңкә кебекләр.*

*Язның алтын ачкычлары,
Җәйгә ачалар ишек.
Җилдә тирбәлә җилдәвек,
Әйтерсең, нәни бишек.*



Борыч

Тәрәзә төбендә пеште
Вак-вак борыч кузагы.
- Борыч кызыл-кызылын,
Каба күрмә кызыгып!

Әни шулай куркытты,
Куркытты, чыгып китте.
Карап калдым тәрәздән,
Капка төбенә җитте.

Борыч гел карап тора,
Гел мине кызыктыра,
Өзеп алуым булды,
Телгә салуым булды,
Уф, авызга ут капты,
- Үләм, - дип чыгып чаптым.
- Тьфү, тьфү, - төкерәм,
Үрле-кырлы сикерәм.

- Су бирегез, су кирәк!
Чабам ары да бире,
Мин акырган тавышка
Әнием кайтты кире.

Суны эчтем чүмечләп,
Эчкәнмендер бер кое,
Җилгә куеп авызны
Ачып яттым көн буе.

Кояш ашаган

Көн буе тышта уйнадым,
Мине кояш ашаган.
Ап-ак битле малай идем,
Кызыл битле ясаган.

Борынның тиресе купты,
Ачыта җилкәм, аркам,
Йоклаганда да авырта,
Йөзтүбән генә ятам.

Әй, сеңлем кызгана мине
Әгәм үзенчә юата:
- Кояшны син ачуланма,
Ул сине бик ярата.

Ашаса да, аз ашаган.
Тешләмәгән, капмаган...
Тәмле малай икән, диеп,
Әле ярый йотмаган.

Алма ничәү

Алия алма өзә,
Тартма төбенә тезә.
Йә, саныйк, булды ничәү:
Бер, ике, өч, дүрт, бишәү.

Алмалар кызыл, тигез,
Алты, җиде һәм сигез.
Булды тугыз, булды ун,
Ун бармак ул - ике кул.



Биек, биек

Мин чиләктән дә биек,
Мин өстәлдән дә биек.
Әнием сыйлап тора,
Мине зур үссен, диеп.

Тик койма биегрәк,
Аңа менәргә кирәк.
Өстенә менеп бассам,
Уңга, сулга күз салсам:

Агач биек тагын да,
Биек Әхмәр тавы да.
Кызыктырып очалар
Кошлар зәңгәр һавада.

Ярар, ярар, очыгыз,
Мин дә үсеп җитәрмен.
Ракетада, сезне узып,
Галәмгә үк китәрмен.

Витаминлы күлмәк

Кызылга ак борчаклы -
Күлмәк матур шулчаклы.
Тегеп бирде әбием:
- Куанып ки, бәбием!
Бик сөенеп кайтам мин,
Күлмәк тулы витамин.

Керпе остахнәсе

Керпе остахнәсе



Беләсездер, керпе йөри,
Алты мең энә тагып.
Тегүче булырга уйлый,
Җайлы бер урын табып.

Йөри торгач, бакчада ул
Бер агач төбе тапкан,
Шул агачка зур итеп
Белдерү язып каккан:

"Бүгеннән монда ачыла,
Тегү остаханәсе".
Җәнлекләр бик сөенгәннәр,
Әй, эттәгенәсе!

Куян килгән, ди, йөгереп,
Ак тун кирәк, дип, кышка.
Тун кимичә, кыш көнендә
Чыга алмыйсың тышка.

Куянга тун бик ошаган,
Килешкән гәүдәсенә.
Мактаган ул тегүчене
Очраган һәрберсенә.

Тиен килгән кечтәнәчләп -
Чикләвек тулы чүлмәк.
Бик тиз арада кирәк, ди,
Аңа бәйрәмгә күлмәк.

Җирән тиеннең күлмәге
Булган, ди, бик килешле.
Керпегә инде, билгеле,
Тагын мактау тиешле.

Чебен-черки, кигәвеннәр
Барсы итәк тектерә.
Көзге алдында бизәлдәп,
Кабат-кабат тикшерә.

Керпе-оста тегеп биргән
Әтәчләргә күнитек.
Песиләргә йомшак башмак,
Каз-үрдәкләргә читек.

Тавык булырга җыенган
Чебиләр сорый калфак.
- Чигеп тә бир, зинһар, - диләр, -
Оят, калфаксыз калсак.

Җәй буе гөрләп эшләгән
Керпе остаханәсе.
Ләкин җәй көзгә авышты,
Әй, эттәгенәсе!

Җыенырга вакыт җиткән,
Йорт кирәк кышкы ялга.
Яфраклардан келәм тукып
Түшәргә кирәк анда.

Яңадан белдерү язды:
"Остаханә ябыла.
Язын эшли башлаячак
Керпе-оста тагын да".

Тамчыларым

Җәй дә, кыш та гел чәчәктә,
Тамчы гөлләрем уңган.
Шушы серле гөлләр белән
Тәрәзә төбем тулган.

Алсу-шәмәхә төсләләр,
Уртасында күзе бар.
Озын керфекләрен сирпи,
Миңа нинди сүзе бар?

Тамчыларым, тамчыларым,
Торалар тамып-тамып.
Кызыгам йөрергә шуны
Алкалар итеп тагып.

Баллы ботка

Үги анадан калышмый
Күкебаш-баллы ботка.
Алсу, шәмәхә һәм зәңгәр-
Өч төс тамган бер башка.

Юкка баллы ботка түгел,
Татлы ширбәт койган ул.
Шөпшә, кортларга булыр, дип,
Азык салып куйган ул.



Шайтан таягы

Шайтан таянып йөргәнме,
Чәнечкеле сабагы.
Үткән-сүткәннәрне чәнчеп
Кала шайтан таягы.

Ә бал кортын кара әле:
Очып килде, кунды бит.
Мендәр итеп чәчәнә
Башы белән чумды бит.

Без-з-без-з итте, безләде,
Татлы балын эзләде.
Уклы-чәнечкеле дуслар
Аңлаштылар үзләре.

Сусыннар

Салават күпере белән
Тиңләгән грек халкы.
Шәмәхә сусын-ирисләр
Мондый исемгә хаклы.

Шундый нәфис, шундый назлы
Һәм горур чәчәк сусын.
Җиргә ямь биреп басар ул,
Май таңы гына тусын.



Кашкарыйлар

Тутәлләрдән
Әй, карыйлар,
Күз чәчәге
Кашкарыйлар.

Ак, шәмәхә,
Күрән һәм ал-
Күзләр җитте,
Сокланып кал.

Күзге җилләр
Уткән юып,
Җилләр йөри
Яфрак куып.

Керфекләре
Челт-челт итә,
Куз яшьләре
Җем-җем итә.

Батыр чәчәк
Кашкарыйлар,
Яшь аша көлеп
Карыйлар.

Нәркисләр

Тау болыннарыннан төшкән
Бакчаларга нәркисләр.
Ак нур сипә, сары күзле,
Бигрәкләр дә нәфисләр.

Миләүшәләр

Зәңгәр чәчәк-миләүшәләр
Кышкы йокыдан туйган.
Күзеңне ачып йомганчы
Чәчәк атып та куйган.

Озын, олы чәчәкләргә
"Уз"-дип юл биреп кенә,
Тыйнак кына елмаялар,
Зәңгәрлек сирпеп кенә.

Җәй буе да, көз буе да,
Чәчәктә миләүшәләр.
Ак кар астында да алар
Яшәргә көрәшәләр.

Пион

Кичтән пион куагында
Бүрткән иде бөреләр,
Ә иртәнгә ачылганнар,
Ал йодрыктай эреләр.

Учак ялкыны капкандай,
Бакчам кызыл, ал төстә.
Бөдрә пионнар коена
Таң нурында хуш искә.

Бүре җиләге

Кып-кызыл матур җиләкләр
Чакырып янып тора.
- Өзеп ал мине, аша,-дип
Ерактан кызыктыра.

Тыштан бик матур булса да,
Эче агулы, зәһәр.
Бүре үзе ашар иде,
Файдалы булса әгәр.

Лалә

Кызалак, лалә, байчәчәк-
Барсы да синең исем.
Яратам сине-нигәдер,
Башкага китми исем.

Үсәсең кайнар Әфганда,
Тауларда, далаларда.
Үз күргән, якын чәчәк син
Голланд томанында да.

Минем бакчамны бизисең
Иртә язда уянып.
Ал, кызыл, сары кәсәләр
Тора кояшта янып.

Табышмаклар

Яшел буяулы тар өйдә
Түп-түгәрәк туганнар.
Шарт-шарт җиргә сикерергә
Күзне көтеп торганнар.
(Борчак)

Балта түгел, чүкеч түгел,
Тук-тук итә урманда.
Кайрысын ачып агачның,
Кортлар чүпли ул анда.
(Тукран)

Чыр-чыр киләм, торбагызга
Чуп-чар, ботак тутырам.
Озак якмыйча торсагыз
Оя ясап утырам.
(Чәүкә)

Бүлмәбездә ак сандык,
Без аңа ит-май салдык,
Тышта җәй, кояш - ялкын,
Сандыктан чыга салкын.
(Суыткыч)

Кайнар кое улагыннан
Кайнар су агып чыга.
Ә тирәсендә сыйлана
Зурлар һәм бала-чага.
(Самовар)

Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

Индекс - 31700
Тираж - 2800